**Шәһәр күләмендә**
**биология фәненнән үткәрелә торган**
**олимпиаданың мәктәп этабы сораулары**
**2017-18 уку елы**

**8 сыйныф**

**Биремнәрне үтәү өчен 3 сәгать вакыт бирелә.**
**Иң югары балл – 45 балл.**

**1 өлеш.**

**1. Бөтен тере организмнар өчен хас булган үзенчәлекләр:**
а) актив хәрәкәтләнү;
б) туфрактан минераль тозларны үзләштерү;
в) сулау, туклану, үсү, үрчү;
г) неорганик матдәләрдән органик матдәләр синтезлау.

**2. Пасленчалар һәм розачалар семьялыгына кергән үсемлекләр нинди класска карыйлар?**
а) икеөлешле,
в) берөлешле,
б) абагалар,
г) ылыслы үсемлекләр классына.

**3. Ни өчен суүсемнәрне иң гади төзелешле үсемлекләр диеп саныйлар?**
а) аларның тукымалары һәм органнары юк,
б) аларда фотосинтез көндез генә бара,
в) суда гына яшиләр,
г) күзәнәкләрендә цитоплазма, төш, хлоропластлар бар.

**4. Усемлек тукымасының кайсысы һәрвакыт бүленеп тора?**
а) туплаучы,
в) үткәруче,
б) ясалгыч,
г) механик.

**5. Күп орлыклы җимешләр:**
а) тузганакта,
в) кукурузада,
б) бодайдаг) фасольда.

**6. Соя һәм арахис орлыклары нинди матдәләргә бай?**
а) май һәм углеводларга,
в) углеводлар һәм майга,
б) аксым һәм майга,
г) минераль тозларга.

**7. Оешма чәчәкле үсемлекләр семьялыгына хас билгеләр:**
а) кәрзин чәчәк төркеме,
б) чук тамыр системасы,
в) яралгыда бер орлык өлеше,
г) тамырларда төерчек бактерияләр булу.

**8. Нинди хайван җәй көне дә йоклый?**
а) бүре,
в) йомран,
б) кушаяк,
г) әрлән.

**9. Нинди хайван аша кеше эхинококк белән зарарлана ала:**
а) сыер, в) эт,
б) мәче, г) балык.

**10. Киль сөяге нинди кошта булмый:**
а) страуста, в) челәндә,
б) үрдәктә, г) тавыкта.

**11. Эчәккуышлыларга нинди симметрия хас:**
а) билатераль симметрия,
б) радиаль симметрия,
в) кайбер төрләрдә билатераль, башкаларда радиаль симметрия,
г) тәннәре симметрияле түгел.

**12. Нинди яссы суалчанның үсешендә личинка стадиясе булмый?**
а) планария, в) эхинококк,
б) үгез тасма суалчан, г) бавыр имгеч суалчан.

**13. Нинди умырткалыларда урта колак барлыкка килә:**
а) балыкларда, в) сөйрәлүчеләрдә,
б) җир-су хайваннарында, г) кошларда.

**14. Тышкы скелет барлыкка килә:**
а) яңгыр суалчанда, в) бавыр имгеч суалчанында,
б) үрмәкүчтә, г) актиниядә.

**15. Кан плазмасының аксымы – фибриноген**
а) кислородны йөртә,
б) организмның иммунитетын көчәйтә,
в) кан оюпроцессындакатнаша,
г) углекислый газныңконцентрациясен киметә.

**16. Йогышлы авыруларга бирешмәгән кешеләрдә:**
а) матдәләр алмашы интенсив бара, в) тән температурасы югары була,
б) тискәре резус-фактор бар, г) канда антитәнчекләр (антитела) була.

**17. Сөяк һәм кимерчәк тукымасы нинди тукымалар төркеменә керә?**
а) мускул, в) эпителиаль,
б) тоташтыргыч, г) нерв.

**18. Бүлеп чыгару системасына нинди орган керә?**
а) йөрәк, в) бөер,
б) бавыр, г) ашказаны.

**19. Артериянең диаметрын үзгәртүче тукыма:**
а) эпителиаль, в) шома мускул, б) тоташтыргыч, г) аркылы-буй мускул.

**20. Үт сыекчасы ашкайнатуда нинди роль үти?**
а) майны тарката,
б) углеводларны тарката,
в) майны эмульциягә әйләндерә, ферментларны активлаштыра,
г) су сеңдерү процессын тизләтә.

**2 өлеш.**
**Берничә дөрес җавап сайлагыз.**

**1. Чук тамыр системасы кайсы үсемлекләргә хас?**
1) арыш, 2) көнбагыш, 3) мәк, 4) бодай, 5) суган, 6) кишер.

**2. Бактерияләр барлыкка китеруче авырулар:**
1) столбняк, 2) чума, 3) грипп, 4) СПИД, 5) холера, 6) бруцеллез.

**3. Яшел суүсемнәрнең күзәнәгендә нинди органоидлар бар?**
1) төш, 2) хроматофор, 3) вакуоль, 4) митохондрия, 5) Гольджи аппараты,
6) эндоплазматик челтәр.

**4. Клоакалы хайваннарны сайлагыз:**
1) кимерчәкле балыклар, 2) бакалар, 3) крокодиллар, 4) кошлар, 5) сөякле балыклар, 6) ерткыч имезүчеләр.

**5. Радиаль симметрия нинди хайваннарга хас?**
1) эчәккуышлыларга, 2) яссы суалчаннарга, 3) моллюскларга, 4) бөҗәкләргә,
5) кыслаларга 6) үрмәкүчләргә.

**3 өлеш.**
**Дөрес җөмләләрне сайлап алыгыз.**

1. Анаэроб бактерияләр кислородсыз тирәлектә яши алмыйлар.
2. Ачыкорлыклы үсемлекләр арасында мәңге яшел һәм яфрак коючы төрләр бар.
3. Яссы суалчаннарның имгечләре паразит формада яшәү өчен җайлашу булып тора.
4. Яшәеш циклларында җенси һәм җенессез буыннар чиратлашуы яссы суалчаннар һәм эчәккуышлыларда очрый.
5. Тоташтыргыч тукымадан тир, май бизләре һәм сөякләр тора.